Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегенең
Рус Акташы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
КАРАРЫ

27 ноябрь 2020 ел №6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының35 статьясы,2020 елның 16 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта, 2020 елның 17 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта, 2020 елның 18 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта, 2020 елның 19 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта,2020 елның 20 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта,2020 елның 21 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта, 2020 елның 23 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта, 2020 елның 24 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта, 2020 елның 25 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта, узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә:

"Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Рус Акташы авыл җирлегенең Рус Акташы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, юлларны норматив хәлгә китерү, Рус Акташы авылында урам яктырткычларын норатив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү?"соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 3059 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 1549 кеше, бу 52% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 1381 «РИЗА»позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 168 «КАРШЫ»позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегенең Рус Акташыторак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегенең Рус Акташы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган яшәүчедән үзара салым средстволарын елда 500 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрнебашкаруга юнәлдерергә:су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, юлларны норматив хәлгә китерү, Рус Акташы авылында урам яктырткычларын норатив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү.

4.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, Рус Акташы авылы, Төзүчеләр урамы, 14 нче йорт; Комсомольская урамы, 23а йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукыйактларырегистрынакертүөченҗибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислекитүче С.А. Белоногов